ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 сентября 2024 г. № 5728

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3676 номерлы Карары белән расланган сатулар үткәрмичә муниципаль милектәге җир участогын арендага, түләү нигезендә милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3676 номерлы Карары белән расланган сатулар үткәрмичә муниципаль милектәге җир участогын арендага, түләү нигезендә милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.8.2.1 пунктның 8 пунктчасында «төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 нче кушымтада:

- 1, 2, 3, 5, 19, 20 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;
- 27 пунктны кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;
- 28, 29, 30 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 5 сентябрендәге
5728 номерлы карарына
кушымта

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 27. | Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктның 13 пунктчасы | Арендага | Территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат | Аңа карата комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә барлыкка килгән җир участогы | Территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә<br><br><*> Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир участогы турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә<br><br><*> Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты<br><br><*> Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева